КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 20 июнь г.Казань № 589

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Бу карар (Тәртипнең 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 7 пунктындагы өченче абзацыннан һәм 26 пунктыннан тыш) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин